ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**18.04.2022**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 939**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 11 декабрендәге «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2854 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160[1] статьясындагы 3[2] пунктының дүртенче абзацы нигезендә Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының «2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында» 2021 елның 11 декабрендәге 2854 номерлы карары белән расланган 2022 елга һәм 2023 һәм 2024 еллар план чорына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы бюджеты керемнәренең төп администраторлары исемлегенә (алга таба - Исемлек) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемлектән түбәндәге эчтәлекле юлны төшереп калдырырга:

| | | |
|---|---|---|
| «805 | 2 02 45160 13 0000 150 | Башка дәрәҗәдәге хакимият органнары тарафыннан кабул ителгән карарлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән өстәмә чыгымнарны компенсацияләү өчен шәһәр җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар» |

1.2. Түбәндәге эчтәлекле юллар белән Исемлекне тулыландырырга:

| | | |
|---|---|---|
| «805 | 2 02 49999 13 0000 150 | Шәһәр җирлекләре бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар» |

2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2022 елның 01 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. ЗМР Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлегенә әлеге карарны «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зеленодольск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы җитәкчесе О.П. Дёгтевага йөкләргә.

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе И. Р. Ганиев